ГЛАВА КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

07.10.2020 | д. Канаш | № 1

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Йолдыз авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Йолдыз авылында 2020 нче елның 22 нче октябренә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Йолдыз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы:

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы, Канаш авыл җирлеге Йолдыз авылы Лесная урамы буенча юлларга вак таш җәю

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Йолдыз авылы, Лесная урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында 10.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков